# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Хәсәншә торак пунктында үзара салым акчалары кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 4

«10» октябрь, 2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гому принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ сан Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасы җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ сан Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарст Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирл муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципа районы Югары Ушма авыл җирлегенең Хәсәншә торак пунктында 20 елның «10» октябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алард файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыен беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Уш авыл җирлеге Хәсәншә торак пункты территориясендә яшәү урыны буен теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөе Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Вата сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары кү балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армияс сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2024 елда 500 (биш йөз) сум күләменд үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттә мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Хәсәнша торак пунктында, зиратны койма белән әйләндәреп алу: ( материал сатып алу, эш өчен түләү)
- Хәсәнша торак пунктында урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру яки алыштыру;
- Хәсәнша торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 42 кеше кертелгән;
гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 36 кеше, 86% тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 36 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0граждан тавыш бирде;

Бәян ител әннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең Хәсәншә торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең Хәсәншә торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Хәсәншә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Хәсәнша торак пунктында, зиратны койма белән әйләндәреп алу: ( материал сатып алу, эш өчен түләү)
- Хәсәнша торак пунктында урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру яки алыштыру;
- Хәсәнша торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Югары Ушма авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе

И.З.Исмэгыйлев